*Кушымта*

**Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының**
**2021 елның 1 яртыеллыгында**
**гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эше турында**
**СТАТИСТИК БЕЛЕШМӘЛӘР***

| Министрлык/Ведомство | 2021 елның 1 яртыеллыгында гражданнардан кергән барлык мөрәҗәгатьләр** | 2020 елның 1 яртыеллыгында гражданнардан кергән барлык мөрәҗәгатьләр | Телдән мөрәҗәгать итүләр (шәхсән кабул итү һәм телефон аша алынганнар) | Шул исәптән җитәкче тарафыннан шәхсән кабул ителү | Шул исәптән видеоконференцэлемтә системасы аша кабул ителү | Язма мөрәҗәгатьләр | Шул исәптән Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән*** | Контрольгә алынган | Урынга чыгып тикшерелгән | Уңай хәл ителгән |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 701 | 1403 | 27 | 5 | 3 | 674 | 265 | 701 | - | 46 |

* **Данные с 1.01.2021 г. по 30.06.2021 г.**
**Барлык мөрәҗәгатьләр = язма мөрәҗәгатьләр һәм телдән мөрәҗәгать итүләрнең** суммар күләме.
***Интернет кабул итү бүлмәсе** язма мөрәҗәгатьләр исәбенә керә.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына 2021 елның 1 яртыеллыгында
гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә
АНАЛИЗ

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына (алга таба – Министрлык) 2021 елның 1 яртыеллыгында гражданнардан **701** мөрәҗәгать кергән, бу 2020 елның шушы чоры белән чагыштырганда (**1403** мөрәҗәгать) 2 тапкырга кимрәк. Шулардан **674** мөрәҗәгать язма рәвештә, шул исәптән Интернет кабул итү бүлмәсе аша - **265** мөрәҗәгать кергән.

Татар телендә кергән **3** мөрәҗәгать каралган.

Гражданнарны кабул итү Министрлык җитәкчелеге тарафыннан билгеләнгән көннәрдә расланган график нигезендә гамәлгә ашырыла.

Министрлык җитәкчелеге тарафыннан турыдан-туры **21** кеше кабул ителгән. Видеоконференцэлемтә режимында гражданнар ике тапкыр кабул ителгәннәр, алар барышында **3** кеше үз сорауларына җаваплар алганнар. Теләче муниципаль районына чыгып уздырылган кабул итү вакытында 3 кеше үз сорауларына җаваплар алган.

Җаваплар **349** мөрәҗәгатькә җибәрелде, шул исәптән **46** мөрәҗәгать буенча уңай карар кабул ителде, **303** мөрәҗәгатькә аңлатмалар бирелде. Профильле оешмаларга **231** мөрәҗәгать юлланды. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшчәнлегенә бәйле **10** мөрәҗәгать буенча тиешле чаралар күрелде. Балигъ булмаган гражданнар катнашында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәт алу турында **16** мөрәҗәгать хупланмады. Җәмәгать судьялары аппаратлары эшенә карата элегрәк җибәрелгән шикаятьләр буенча эшне туктату турында **28** гариза каралды һәм **28** шикаять кире алынды. Мәгълүмати характердагы **15** мөрәҗәгать игътибарга алынды. Хәзерге вакытта **24** мөрәҗәгать каралу стадиясендә.

Килеп ирешкән корреспонденция мөрәҗәгатьләрдә күтәрелгән мәсьәләләр һәм Министрлык компетенциясен исәпкә алып карала.

Шикаятьләр, гаризалар һәм тәкъдимнәр түбәндәге тематикалар буенча кергән.

**Саклану, куркынычсызлык, законлылык - 33,70%** (2021 – 244, 2020 – 899).

«Иминлек һәм хокук тәртибен саклау» тематикасы буенча 46 сорау керде. Аларның унысы санитар-карантин контролен тормышка ашыру, аерым алганда гражданнарның яңа коронавирус инфекциясе таралуны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар белән килешмәүләре белән бәйле.

140 мәсьәлә суд системасына кагылышлы, шуларның 137се - федераль һәм җәмәгать судьялары һәм аларның аппаратлары эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр һәм шикаятьләр.

55 мәсьәлә прокуратура, юстиция органнары, нотариат һәм адвокатура эше белән бәйле.

Җәзаларны үтәү органнары эшчәнлегенә бәйле рәвештә 3 сорау керде.

**Социаль өлкә - 25,28%** (2021-184, 2020 – 665).

Сәламәтлек саклау өлкәсенә караган мөрәҗәгатьнең 39ы халыкның санитар-эпидемиологик иминлегенә кагылышлы: җәмәгать урыннарында битлек һәм перчаткалар кию таләбе белән килешмәү; шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү таләбе.

32 мөрәҗәгать балигъ булмаганнар катнашында хезмәт эшчәнлеген башкаруга рөхсәт бирүгә кагыла.

31 мөрәҗәгать балаларга пособиеләр һәм компенсацияләр түләү, никахны теркәү һәм өзү белән бәйле.

63 мөрәҗәгать социаль тәэмин итү һәм социаль иминләү белән бәйле: күп балалы гаиләләргә, авыр хәлдә калган гражданнарга, эшсезләргә, аз керемле гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү, түләүсез юридик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре турындагылар.

19 мөрәҗәгать халыкның хезмәте һәм мәшгульлеге, эшсез гражданнарга социаль түләүләр мәсьәләләре белән бәйле.

**Дәүләт, җәмгыять, сәясәт - 22,38%** (2021 – 162, 2020 – 557).

Әлеге тематик блок буенча кергән мөрәҗәгатьләр элек җибәрелгән шикаятьләрне туктатуга, шулай ук иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегенә, башкарма хакимият органнары, муниципаль хакимият органнары һәм вазыйфаи затлар эшчәнлегенә бәйле.

**Икътисад - 15,33%** (2021 – 111, 2020 – 303).

Артык тотып калынган яки түләнгән акчаларны кире кайтару 61 граждан өчен мөһим булган. Калган 50 мөрәҗәгать җирдән файдалану, табигатьне саклау, сәүдә, төзелеш, көнкүреш хезмәте күрсәтү, транспорт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә кагыла.

**Торак-коммуналь өлкә - 3,31%** (2021 – 24, 2020 – 47).

Төп мәсьәлә - торак-коммуналь хуҗалык өчен түләүгә субсидияләр, ипотека кредиты алу, күп фатирлы йортны ремонтлау сыйфаты, ятим балаларны, инвалидларны торак белән тәэмин итү.

2020 елның 1 яртыеллыгында COVID-19 коронавирус инфекциясе таралу чорында кабул ителгән чикләү чаралары киң җәмгыяви резонанс алды. Үз чиратында, 2021 елның 1 яртыеллыгында мөрәҗәгатьләр керү саны кимү кайбер чикләүләрне бетерү - изоляцияләүне бетерү, сәүдә, төзелеш, көнкүреш һәм транспорт хезмәте күрсәтү, мәдәният объектлары, уку йортлары эшчәнлеге яңару белән аңлатыла.

Гражданнардан Министрлыкка кергән барлык мөрәҗәгатьләр дә «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә каралалар.